Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№8 (138)

21 май 2015 ел

## • Вакыйгалар эзеннән

15 нче майда КФУда **«РОССИЯ ҺӘМ ЧИТ ИЛ ИРАНИСТИКА БЕЛЕМЕН ӨЙРӘНҮНЕҢ АКТУАЛЬ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ»** дип исемләнгән фәнни-гамәли конференция үз эшчәнлеген башлап җибәрде. Конференция кысаларында Россия, Әрмәнстан, Казахстан, Таҗикстан һәм Бөекбританиядән килгән алдынгы галимнәр чыгыш ясады. Кембридж университеты каршындагы Пемброк колледжы җитәкчесе **ФИРҮЗӘ МӘЛВИН** сәламләү сүзләрендә Казанның Иранны өйрәнү буенча төп үзәк булуын ассызыклады. Конференция эшчәнлегендә Иран Республикасы вәкиллегенең беренче сәркатибе **ХӘМИД ЗАНГАНЕХ**, Иранның Россиядәге илчесе **МЕХДИ СӘНӘИ**, Иран Республикасының генераль консулы **РӘСҮЛ БӘГЕРНЕҖАД ШАЯН** да катнашты.

• • • •

**КФУ** һәм **«СКОЛКОВО»** Татарстан Республикасы хөкүмәте вәкилләренә белем бирү эшен башлап җибәрделәр. КФУ тарафыннан уздырылган әлеге чараның ачылу тантанасында ТР президенты вазифаларын башкаручы **РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ**, «Сколково» идарә мәктәбе ректоры **АНДРЕЙ ШАРОНОВ**, КФУның беренче проректоры **РИЯЗ МИНЗАРИПОВ**, дәүләт һәм муниципаль идарә буенча югары мәктәп директоры **ИГОРЬ ПРИВАЛОВ** катнаштылар. Оештыручыларның сүзләренә караганда, программа биш модульдән тора. Һәр модуль өч көнлек укулардан гыйбарәт, ә модульләр арасында ай, ай ярымлык «тәнәфес» булачак. Квалификация күтәрү программасы ноябрьдә тәмамланыр дип көтелә.

• • • •

18 нче майда **КФУ ЯПОНИЯНЕҢ ФӘННИ ҮЗӘК ҺӘМ БИЗНЕС-СТРУКТУРАЛАРЫ ВӘКИЛЛӘРЕН** кабул итте. Кунакларны КФУның тышкы эшләр буенча проректоры **ЛИНАР ЛАТЫПОВ**, белем бирү эшчәнлеге буенча проректор **ДМИТРИЙ ТАЮРСКИЙ**, Фундаменталь медицина һәм биология институты директоры **АНДРЕЙ КИЯСОВ**, Мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати системалар югары мәктәбе директоры **АЙРАТ ХӘСИЯНОВ**, Икътисад, идарә һәм финанс институты директоры **НАИЛӘ БАҺАВЕТДИНОВА** каршы алды. Очрашу барышында ике як арасында килешүләр төзелү ихтималлыгы ассызыкланды. Икътисад, идарә һәм финанс институты студентларының Iida Sangyo Co., Ltd. и NC Network Co., Ltd компанияләрендә стажировка узуы турында да сүз алып барылды.

• • • •

Якын Көнчыгыш университетының Нефть һәм табигый газ технологияләре кафедрасы мөдире **МОСТАФА ВЕРСАН КОК** 13-15 нче майда **КФУ**да **ЭШЛЕКЛЕ КИҢӘШМӘДӘ КАТНАШТЫ**. Очрашу барышында уртак проектлар һәм Америка, Европа, Азия, ТР территорияләрендә табылган нефтьне эшкәртү юллары мәсьәләсе дә каралды.

• • • •

Алтай Республикасының Таулы Алтай шәһәрендә 12-16 нчы майда **«ФИЛОЛОГИЯ. РФ ХАЛЫКЛАРЫ ТЕЛЛӘРЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ (ТӨРКИ ТӨРКЕМ)»** Бөтенроссия студентлар олимпиадасы узды. Бу бәйгедә университетыбызның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты студентлары да катнашты. Себер якларына сәяхәтнең нәтиҗәләре шатландырырлык: **АЙГӨЛ САЛИХОВА** (4 нче курс) – «Иң яхшы фәнни эш», **АЙГӨЛ АБДРАХМАНОВА** (5 нче курс) «Әдәбият белеме өлкәсендә иң тирән белем өчен» номинациясендә җиңү яуладылар. 5 нче курс студенты **РУФИНӘ ГАБДРАХМАНОВА** шәхси беренчелектә икенче урынга чыкты.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*




■ Сулдан уңга: Мәрьям Насыйрова һәм Эльвира Гайнетдинова. Влад Михневский фотосы

# *Хәтер – мәңгелек*

19 нчы майда, Татарстан матбугаты көнендә, КФУ музееның актлар залында Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышланган «Җиңү уты буыннар хәтерендә» дип аталган әдәби-иҗади конкурсның җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы узды. Студентлар, аспирантлар, мөгаллимнәр арасында уздырылган бәйгедә 20 меңнән артык кеше катнашты. Шуларның 70е җиңүчеләр булган, 210 кеше лауреат исемен алган. Җиңүчеләрне герой-шәһәр Волгоградка сәяхәт юлламасы белән бүләкләделәр, ә лауреатларга истәлекле бүләкләр тапшырылды.

Шәхес

# Төп игътибар – сыйфатка!

**Алсу НУРГАТИНА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Без сессия, диплом дип йөргән арада, Татарстан матбугаты көне узып киткән икән бит. Бу көн – барлык каләм чарлаучы коллегаларыбыз өчен зур бәйрәм. Әйе, бүгеннән нәкъ менә «коллегалар» дип атыйм әле үзләрен. Журналист, «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире Миңназыйм Сәфәров та үзенең һәр студентын коллегам дип атый икән бит. «Бу аларга канат куя, араларыбызны якынайта», – ди ул. Казан федераль университетын тәмамлаган, аның белән тыгыз элемтәдә торган Миңназыйм абый Сәфәровның үзе белән дә очраштым.



**– Миңназыйм абый, Сез урта мәктәпне тәмамлап килгән гади студенттан «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире булу дәрәҗәсенә ирешкәнсез. Студенттан баш мөхәррирга хәтле үтелгән юл хакында ниләр әйтер идегез?**

– Мин инде мәктәптә укыганда үземнең журналист буласымны белә идем. 5 нче сыйныфтан ук язмаларым басылып килде. 9 нчы сыйныфта укыганда, мәктәп директоры миңа: «Син журналист булырга тиеш», – дип әйтте. Шулай ук укытучы булырга һәм биергә дигән теләк бар иде. Журналистика минем бар хыялларымны тормышка ашырды: студент елларында мин «Каз канаты» ансамблендә биедем, зур сәхнәләрне дер селкеттек, хәзер укытам. Журналистика ул – җәмгыятьтә бик зур статус. Баш мөхәррир булырмын дип күз алдына да китермәгән идем... «Татарстан яшьләре»ндә 20 ел эшләгәч, баш мөхәррир вазифасына чакырып алдылар. Тугыз ай буена ризалашмый йөрдем, чөнки «Татарстан яшьләре» минем өчен бик якын, өем кебек иде. Аннан, ризалашып, яңа урында эшли башладым. Монда да сизелмичә 12 ел үтеп киткән икән инде...



**– Баш мөхәррир булудан кала, әле сез университет белән дә даими элемтәдә торасыз, студентлар укытасыз...**

– Студентларга карап, яшь чагымны таныган мизгелләр еш була. Алар урынына мин һәрвакыт үземне куеп карыйм. Студент белән укытучы арасында беркайчан да дистанция булмаска тиеш. Аларга һәрвакыт «коллегалар» дип эндәшәм. Бу аларны укытучыга якынайта, үстерә, каушауларын оныттыра. Мин үзем белгәнне өйрәтергә тырышам, кайсы очракта нишләргә икәнлеген аңлатып, тормыш мисаллары белән үреп барам. Журналистика – белемнәрне механик рәвештә бергә тоташтырган һөнәр генә түгел, ул йөрәк кушканча эшләү, күңел халәте. Ә синең йөрәгең кешегә ярдәм итү, аны тану, ачу, ышандыра алу сыйфатлары белән бергә тибәргә тиеш. Әгәр аларның берсе генә булмаса да, син журналист түгел. Кеше сиңа ышанса гына, барысын да сөйләп бирә ала.

**– Бүген журналистикага кемнәр килә?**

– Студентлар күпкә әзерлеклерәк булып киләләр, күп беләләр. Хәзерге вакытта мөмкинлекләр күбрәк, интернет бар. Ләкин алар замана чире белән авырыйлар: таркаулар, барысына да өлгерергә тырышалар, мин-минлек көчле... Җәмгыятькә хас авырулар аларга да күчкән. Ләкин журналист беркайчан да андый авыруларга бирешергә тиеш түгел. Журналистлар – икенче төрле токым.

**– Телевидение, газета, университет. Кайсы күңелгә якынрак?**

– Аерып кенә әйтә алмыйм, барысы да күңелгә якын. Барысы да журналистикага барып тоташа.

**– Татар матбугатының торышы хакында сөйләп үтсәк...**

– Минем уйлавымча, журналистиканың таләпләре Америкада да, Татарстанда да бер булырга тиеш. Матбугат чарасының кайберсен «сагыну», кайберсендә «берьяклы гына сүгү» итеп, «татар пәрәмәче» ясау кирәкми, җәмгыять мәнфәгатьләрен истә тоту кирәк. Журналистика һәрвакыт халыкның терәге булды һәм булачак. Басма матбугат бетә дип яшәү дөрес түгел, бу телевизордан «дөнья бетә» дип сөйләү кебек. Газета – ул кешелекнең яшәү мәйданы.

**– Коллегаларыбызга теләк итеп...**

– Хәзерге дүрт курс күз ачып йомган арада үтеп тә китә. Шушы вакытта мөмкин кадәр күбрәк белемне үзеңә алып, сеңдереп калырга. Кызыксынучан булырга, максатыңа омтылып яшәргә. Ятсаң да, торсаң да, журналист булуыңны онытмаска кирәк.

# Журналистика – ул яшәү рәвеше

**Ландыш ВӘЛИЕВА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Татарстан гаммәви мәгълүмат чараларында үз эшләренә чын күңелдән бирелгән талантлы кешеләр эшли. Журналистика – ул һөнәр генә түгел, ул яшәү рәвеше дә!

Быел татар журналистикасы үзенең 110 еллык юбилеен билгеләп үтә. 1905 нче елның 19 нчы маенда беренче гомумроссия татар басмасы – «Нур» газетасын чыгарырга рөхсәт алынган. Татарстан журналистларының һәм газета-журналлар нәшер итү белән шөгыльләнүче барлык һөнәр ияләренең профессиональ бәйрәме әнә шул датага бәйле.

«Журналист» белгечлеге дипломы медиа тармагында эшләү, матбугат, телевидение, радио һәм интернет басмаларда иҗат итү, көн кадагындагы вакыйгалардан хәбәрдар булу мөмкинлеген бирә. Университетта нәкъ шушы белгечлек буенча белем алуыма мин бер дә үкенмим. Журналист хезмәте авыр, әмма кызыклы. Эфирда әйтелгән яки газета полосасында басылган һәр сүз өчен журналист зур җаваплылык тота. Тик һәрвакыт эзләнүдә булу, яңалыкка омтылу, күренекле кешеләр белән аралашу, җәмәгатьчелекне борчыган сорауларга җавап эзләү, укучылар белән әңгәмәләр оештыру – бу минем яшәү рәвешем дисәм дә, ялгыш булмас.

Татарстанда меңгә якын гаммәви мәгълүмат чарасы эшли. Сүз дә юк, рус һәм чит ил массакүләм чараларыннан татар телендә чыга торганнары әлегә калыша. Шуңа да карамастан, Татарстанда нәшрият эшчәнлегенең күләме елдан-ел арта, яңа теле- һәм радиотапшырулар, басмаларның интернет һәм iPad-версияләре барлыкка килә, мультимедиа технологияләр үсеш кичерә, даими рәвештә полиграфия мөмкинлекләренең техник яңарыш процессы бара. Татарстандагы вакыйгалар, республика һәм федераль дәрәҗәдән тыш, чит илләрдә дә чагылыш таба. Шул рәвешле татар гаммәви мәгълүмат чаралары да тәэсир итү даирәсен киңәйтә, безнең мөмкинлекләр арта.

КФУның татар телендә иҗат итүче журналистлар укытып чыгаруы татар даими басмалары, алай гына да түгел, илебезнең социаль, сәяси һәм икътисадый үсеше өчен дә бер стимул булып тора. Киләчәктә без дә шул тәҗрибәле журналистлар төркеменең бер өлеше булырбыз дип ышанып каласы килә.

Журналист сүзенең халыкның акылына һәм йөрәгенә йогынты ясау көче зур. Ләкин ул сүзнең һәр яклап үлчәнгән, дөрес булуы зарур, ул кешеләргә яктылык һәм яхшылык алып килергә тиеш.

Татарстан Республикасының барлык журналистларын бәйрәм белән котлап, каләмнәренә илһам, даими эзләнүләрендә уңышлар телибез.



**✦ «Бәллүр каләм»**

*19 нчы майда Казанда Татарстан журналистлары һәм төрле матбугат чараларында иҗат итүчеләр өчен үткәрелгән «Бәллүр каләм» – «Хрустальное перо» XVIII бәйгесенә йомгак ясалды. Бәйге, 1998 елдан башлап, ел саен уздырыла. Быел «Бәллүр каләм»нең Гран-при иясе дип жюри тарафыннан «Республика Татарстан» газетасының баш редакторы урынбасары Владимир Устиновский билгеләнде. Җиңүчегә машина бүләк иттеләр.*

Очрашу

# «Һәр югары уку йорты – уникаль»



**Илмир ВӘЛИЕВ,** Математика һәм механика институты

Узган атнада КФУга Россия Федерациясенең алдынгы университетларының конкуренциягә сәләтлелеген арттыру буенча Совет рәисе урынбасары Андрей Волков рәсми визит ясады.

Эшлекле сәфәр барышында ул университетның медицина кластерлары, физика, химия кебек фән өлкәләрендәге казанышлары белән танышты. Ул уку йортының үсешен, төрле профессиональ әзерлек юнәлешләре булдырылуын, фәнни тикшеренүләргә саллы урын бирелүен хуплады. Һәм, шуннан чыгып, кунак КФУның **5-100 проектындагы** зур өстенлеген ассызыклады.

**Андрей Волков** – РФ мәгариф һәм фән министры киңәшчесе, «Сколково» Мәскәү идарә мәктәбе ректоры. Озак еллар дәвамында фән өлкәсендә зур уңышларга ирешкән галим конкуренциягә сәләтлелекне арттыруга бәйле актуаль мәсьәләләр өстендә эшләвен дәвам итә. **5-100 проекты** бүгенге көндә әйдәп баручы уку йортларының конкурентлык позицияләрен арттыруны максат итеп куя. Университетның да әлеге проект кысаларында максатлары зурдан. А.Волков сүзләре бунча, һәр югары уку йорты – үсеш институты, һәрберсе – уникаль берәмлек. Ә КФУның әлеге проекттагы мөкинлекләрен ул болай бәяли: «КФУ көннән-көн яңа темплар белән үсә. Төрле тармаклы структурасы булган әлеге уку йорты – алдынгы университетларның берсе. Аның өстенлеген дә нәкъ менә студентларның төрле өлкәләргә ориентлашуы һәм белем алуга теләк уятучы мөмкинлекләр артуын билгели».

Эксперт университетта профессиональ белем бирүгә бик зур игътибар булуын әйтеп китте. Бүгенге көндә югары белем бирү биш төп принцип буенча эш алып бара: критик, экологик фикерләүне үстерү, әхлаклылык, толерантлык кебек сыйфатларны булдыру һәм системалы ысулга якынаю процессын активлаштыра.

Утырыш барышында спикер 5-100 проектының бүгенге нәтиҗәләрен яктырткан презентация тәкъдим итте. Ул уку йортларының берничә уртак кимчелекләренә тулырак тукталды. Алар арасында – университетларның я белем бирүче, я тикшеренүче уку йортларына бүленүе, төрле институтлар белән хезмәттәшлекнең җитәрлек дәрәҗәдә булмавы, «позицион» дип атала торган берьяклы юнәлешнең барлыкка килүе ассызыкланды.

Апрель азагында Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында шигырь бәйрәме оештырылды.

# Тукай турында без бик күп язабыз...

Мәрьям НАСЫЙРОВА, Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Бәйрәмдә Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, РФнең атказанган мәдәният эшлеклесе **Гәрәй Рәхим** дә катнашты.

Ул җыелган кунаклар каршында бик мәгънәле сүзләр әйтте: «Иҗатка тартылуыгыз бик күңелле. Тукай турында без бик күп язабыз. Кайчакта мин хәтта уйлап куям: артыграк язып ташламыйбызмы икән?! Чөнки Тукайны бөек шагыйрь, бөек кеше, бөек шәхес дип һәрвакыт кычкырып торабыз, ләкин аның бөеклеге турында төптән уйламыйбыз. Аның тормышы, яшәве бик күп трагик вакыйгаларга бай. Ул, егерме җиде яшендә бу дөньядан китеп, үзеннән соң берничә дистә томдагы китаплар язып калдырган. Мин гомер буеяздым, менә биш томлык сайланма әсәрләрем чыкты. Аның бөтен язган гомере, күп булса, бер ун ел булгандыр. Әлеге кыска вакыт эчендә шуның кадәр эшләү, әлбәттә, Тукайның бөеклеген күрсәтә».

Шигырь бәйгесе өч номинациядә үтте: татар мәктәпләрен һәм гимназияләрен тәмамлап килгән, татар телен ана теле буларак өйрәнүче студентлар «Татар теле – туган телем», рус телле студентлар «Татар теле – дәүләт теле» һәм үзләренең көчләрен шигырь язуда сынап каравга теләгән студентлар «Авторбашкаручы» номинацияләрендә катнаштылар.

Сәгать ярым барган әлеге тамаша бик тиз, сизелмичә дә үтте. Студентларның һәркайсы үзе сайлаган шигырьне сәнгати якын килеп, көчле, дөрес интонация белән, бөтен күңелен биреп сөйләде. Рус телле студентларның тырышып-тырышып, кайберләренең ватып-сындырып диярлек татарча сөйләүләре аеруча сөендерде. Димәк, башка милләт вәкилләренең телебезгә карата хөрмәте бөтенләй үк юк түгел икән.

Студентлар Г.Тукай, М.Җәлил, Х.Туфан, Р.Миңнуллин, Х.Ширмән кебек шагыйрьләрнең иҗат җимешләрен укыдылар. Сугыш, мәхәббәт, туган тел темаларын яктырткан, шулай ук фәлсәфи эчтәлекле шигырьләр дә яңгырады әлеге бәйгедә.

Бәйрәм ахырында жюри әгъзалары нәтиҗәләрне игълан итте, җиңүчеләргә диплом һәм истәлекле бүләкләр тапшырылды.

# «Халык исән чакта телләр үлә»

Алия МАССАРОВА, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

Шушы арада безгә, 1нче курс студентларына, Төркиянең Измир шәһәреннән килгән Эгей университеты профессорлары белән очрашу бәхете елмайды.

Ни өчен «бәхет» дим? Чөнки Измир – Төркиядә кеше саны буенча өченче урында торган һәм порт зурлыгы белән Истанбулга гына беренчелекне биргән шәһәр. Ә Эгей университеты исә Төркиянең биш алдынгы уку йортлары рәтенә керә. Шуңа күрә хөрмәтле **Мостафа Өнәр** һәм **Озкан Озтектен** белән күрешү безнең өчен зур дәрәҗә.

Очрашуның төп темалары булып, төрки телләрнең дөньяда таралышы, бу телләрдә сөйләшүчеләр саны, тюркология өлкәсендә зур хезмәт куйган галимнәр (Арат Рәшит Рәхмәти, Василий Васильевич Радлов, Банг-Кауп Вилли, Иштван Мандоки Коңгур h.б.), татар һәм төрек телләренең тоткан урыны, тәрҗемә мәсьәләләре торды. Студентларны кызыксындырган төрек теле, Төркия университетлары, андагы уку системасына кагылышлы сорауларга да җавап бирде галимнәребез.



✦ Озкан Озтектен

Мостафа Өнәр белән Озкан Озтектен үзләре дә бик күп төрки телләр белә икән. Мостафа бәй: «Бөтен тюркологлар башка төрки телләрне татар теленнән башлап өйрәнә. Сезгә бу мәсьәләдә җиңел, чөнки ул – сезнең ана телегез», – ди. Озкан бәй исә әнисенең Кырым татары булуын һәм үзенең татар телен Тукай һәм Бабичларны укып өйрәнгәнен сөйләде.

Мостафа Өнәр «Tatarica» фәнни журналының халыкара редакция советы әгъзасы да булып тора, һәрдаим татарлар тормышы белән кызыксынып яши. Ул тыңлаучыларга: «Халык исән чакта телләр үлә, гаҗәеп, әйеме?» – дигән риторик сорау белән мөрәҗәгать итте. Шуңа күрә телебезне саклап калу – аралашу дигән сүз генә түгел, аны фәнни яктан үстерү дә алып барылырга тиеш. «Ун меңгә якын Польша татарлары үзен татар дип атап, татарча бер сүз белми, ә Финляндия татарларының саны 850 кеше тирәсе генә булуына карамастан, алар үз телләрен беләләр, матур итеп сөйләшәләр», – ди. Мостафа Өнәр үзе дә татар филологиясе фәнен Әнкарада басылып чыккан шактый күләмле «Татарча-төрекчәсүзлеге» белән өлеш кертә.

Озтектен бәй белән Өнәр бәйнең Татарстанга килүләренең төп сәбәбе булып, тюрколог Рәшит Рәхмәти Аратның (Рәхмәтуллин Габдерәшит Исмәт улы) 115 еллык юбилее уңаеннан 21-22 нче майда КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында «Рәшит Рәхмәти Арат һәм төрки дөнья» дип аталган халыкара фәнни-гамәли конференциядә катнашу тора. Бу очрашу безгә хәзерге Әтнә районыннан чыккан, Берлин университетында укыган, Төркиядә тюркология фәне башлангычы булып саналган әлеге галимне ачты. Мостафа бәй: «Арат безне монда китерде», – ди. Баксаң, профессор 25 еллап инде Рәшит Рәхмәтинең эшчәнлеген өйрәнә икән.



✦ Мостафа Өнәр



# Юлга чыктык без бергә!

Эльмира ШӘЙМӘРДӘНОВА, Икътисад, идарә һәм финанс институты

Моңа кадәр сәяхәт дигәнне мин палаткада йоклау, көнне җилле салкын һавада уздыру, пешер-пешмәс ризык ашап, ачлы-туклы йөрү дип кенә аңлый идем. Күптән түгел, әлеге фикерне үзгәртер өчен, «Җиде румб» турклубы белән җәяүле сәфәр кылу мөмкинлеге барлыкка килде.

Сәяхәтебезнең башы бик үзенчәлекле булды: 25 нче апрельдә Россия күләмендә «Агач утырт» акциясе узганлыгын һәркем дә хәтерлидер. **Идарә, икътисад һәм финанс институты** студентлары белән берлектә, без – турклуб вәкилләре дә Биектау авыл җирлеге янәшәсендә 1 га мәйданда 1418 үсенте утырттык. Ә аннан соң Кушлавычка, бөек шагыйребез Габдулла Тукай музеена җәяүле сәфәргә кузгалдык. Мүлмә, Урта Сәрдә һәм Кушлавыч авыл җирлекләрендә урнашкан обелискларга туктальп, сугыш кырларында ятып калган батырларыбыз истәлеген яңартырга да онытмадык. Тигез җирдән һәм калкулыклардан йөрү, чатыр кору, учакта кичке аш пешерү, гитарага кушылып җырлау, йолдызлы төн – чын турист тормышының бөтен яклары үзебез татып карадык. Шуңа өстәп, туризм буенча ГТО таләпләрен үтәргә һәм «Россия туристы» билгесенә лаек булырга да өлгердек.

Сәяхәттә катнашучылар үз фикерләрен болай дип белдерде:

**ТИМУР АТАЕВ (Экология һәм табигый байлыклардан файдалану институты):** Җәяүле сәфәргә беренче тапкыр чыктым! Туфракны өйрәнү өлкәсендә белем алгач, юлыбызда очраган туфрак төрләрен күзәтү минем өчен бигрәк тә кызыклы булды. XV-XVI гасыр каберлекләре сакланган зиратта, музейда булу да хәтергә уелып калды.

**МАРИЯ МАРЧЕНКО (Химия институты):** Химия институтында укысам да, туфрак төрләре, табигать үзенчәлекләре турында яңа белемнәр өстиалуым бик куандырды. Күпере булмаган Красна елгасы аша чыгу, табигатьнең янгырлы-карлы көненә түзү дә минем өчен зур батырлык.

**ЗӨЛФӘТ ГАЛӘВЕТДИНОВ (Идарә, икътисад һәм финанс институты):** Ир кеше үз гомерендә өч төрле эш башкарырга: агач утыртырга, йорт салырга һәм ул үстерергә тиеш, диләр. Әлеге гыйбарәне бераз үзгәртеп, «Җиде румб» турклубы вәкиле «Агач утырт» акциясендә катнашырга, Г.Тукай истәлеген яңартырга һәм «Россия туристы» билгесенә лаек булырга тиеш диясем килә.

Апрель ахырында **Казан-Коркачык-Кушлавыч-Казан** юлын җәяү узган һәр студент үз бурычын намус белән үтәде.

# «Мин татарча сөйләшәм!»

Эльвира ГАЙНЕТДИНОВА, Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Казан үзәгендә 10 нчы тапкыр «Мин татарча сөйләшәм» акциясе узды.

Беренче тапкыр ул 2005 нче елда **«Үзебез»** дип аталган яшьләр хәрәкәте инициативасы белән башланып киткән иде. 10 ел эчендә акция татар яшьләрен берләштерүгә һәм сафларын киңәйтүгә ирешкән. Быел без моңа тагын бер тапкыр инандык.

Бу көнне Казанның Бауман урамы шау-гөр килеп торды. Үзебезнекеләр генә түгел, Киров өлкәсеннән, Чувашия һәм Башкортстан республикаларыннан татар яшьләре җыелган. Кунакларның ташып торган энергиясе чараны дәртләндереп җибәрде. Үзләре дә акциядән бик канәгать булуларын белдерделәр: «Без татар телендә сөйләшүгә сусап киләбез. Ә монда чып-чын татар мохите. Рәхәтләнеп, бернинди кыенлыкларсыз, татар телендә сөйләшәбез, татар телендә җырлыйбыз. Хәтта бер кибеткә кереп, юри генә татарча эндәшеп караган идек, татар телендә җавап кайтардылар. Күңелебезгә май булып ятты», – ди безнең милләттәшләр.

«Мин татарча сөйләшәм» акциясе дәртле җырлар, төрледән-төрле уеннар һәм бүләкләүләр белән үрелеп барды. Бу елны Илгиз Шәйхразиев, Иттифак, Оскар, Super tatar, Исмаил, Вероника Кузнецова, Гөлназ Батталова кебек яшь җырчылар чыгыш ясады. Быел акциягә «ШИКӘРные» төркеме кушылды: алар «Тукай рэп укый» дип аталган әр-яңа клипларын һәм җырларын тәкъдим итте. «Мин татарча сөйләшәм» акциясен «Алканат» төркеме үзенең дәртле җырлары белән тәмамлады.



Сәнгать

# «Биючегә сүз әйтмәгез!»

**Диләрә БАТРШИНА,**
Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Казан федераль университеты белән бәйле һәр бәйрәм, һәр чара яки фестиваль дәртле биюләрсез үтми. Көчле хореография, төрле импровизация, чын хисләр – барысы да тамашачыны сүзсез калдырырга сәләтле.



Бию сәнгатенә тартылган студентларның талантын үстерүгә зур өлешне, һичшиксез, укытучылары кертә. Инде ничә буын яшьләрдән профессиональ биюче ясаган шундый хореографларның берсе үз фикерләре белән уртаклашты.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театрының балет труппасы педагог-репетиторы, Казан федераль университетының филология һәм мәдәниятара багланышлар институты доценты **Фәнис Фәткый улы Исмәгыйлев**: «Бию – бөтен кеше өчен дә зарур!», – дип белдерә.

– Бию – ул сәнгатьнең бер төре, рухи шөгыль. Теләсә кайсы биюнең төп максаты – сәнгатьле образ тудыру. Мисалга, әгәр дә мин танго биим икән, димәк, ялкынлы испан егете образына, ә «Яблочко» биюен башкарам икән, текә диңгезче образына керәм.

Биюнең һәр кешегә дә кирәкле булуында шигем юк. Бер киртә генә бар: бик күпләрнең бию буенча укытучылары юк. Бию кешенең матурлыгын күрсәтергә сәләтле. Сәнгать – халыкныкы. Димәк, бию дә, сәнгать төре буларак, халык өчен, ягъни безнең өчен туган.

Төрле сәбәпләр аркасында бии алмаучылар бар. Ләкин алар искиткеч тамашачы. Бию хәрәкәтләренең нәфислеген күрә белү сәләте дә үзе бер югары сәнгать ул.

**– Бүгенге көндә яшьләр заманча бию төрләрен үз итә, ә традицион халык биюләре белән кызыксынучылар кими бара. Бу беренчесе өстенлек итә дигән сүз түгелме?**

– Әлеге сорауга җавап бирералдыннан, заманча бию халык биюләреннән гыйбарәт булуын аңларга кирәк. Заманча биюнең төрләре күп. Мисалга, ирекле бию, урам биюе, латинос, бал биюе һәм башкалар. Ирекле биюнең барлык төрләре дә (мисалга, электро, гоу-гоу, хакка, джампстайл һ.б.) модерн биюеннән барлыкка килгән. Ә модерн, күпме генә теләсә дә, үзенә капма-каршы булган классик хореографияне барыбер юкка чыгара алмады. Моннан да бигрәк, модерн биюен башкаручы труппалар (Бежар балетыннан башлап) барысы да классик элементлар куллана. Ләкин халык биюе – ул барлык төр биюләрнең һәм балетның да төп нигезе дип әйтергә кирәк. Ә минем үземә һәртөрле талантлы хореография якын.

Биюләрнең ничек барлыкка килгәнен белгәннән соң, заманча бию халык биюеннән өстенрәк дип әйтә алмыйбыз. Әгәр дә бию башкарыла икән, димәк, ул кемгә дә булса кирәк: я башкаручыга, я тамашачыга.

**– Яшьләр опера һәм балетка сирәк йөри...**

– Опера һәм балет, иң беренче чиратта, спектакль. Барлык спектакльләр дә театрда куела. Әгәр яшьләр театрга йөрми икән, куркыныч түгел. Үскәч барырлар. Театр – ул татлы хыял.

**– Телевидениедә барган бию проектларына, үзебезнең Татарстанда үткәрелгән «Созвездие-Йолдызлык» фестивалендә карашыгыз нинди?**

– Әгәр дә бию хисабына акча эшли алалар икән, бу бик яхшы дип уйлыйм. «Созвездие-Йолдызлык» фестивалендә килгәндә, ул шул ук финанска бәйле проект. Аның уңай ягы шунда: бию куючылар һәм башкаручылар берберсен чагыштырырга, нәтиҗәләр ясарга һәм нәрсәгә дә булса өйрәнергә өлгерә. Һәр фестивальнең максаты булып, яңа талант ачу һәм аны үстерү тора. Бу эш белән тагын кем шөгыльләнсен?!

**– Сез Казан федераль университетының хореография бүлегендә укытасыз. Талантлы студентлар күпме? Сезнең заман һәм хәзерге яшьләр арасында аерма сизеләме?**

– Мин яшьләр сәнгате яклы. Һәрвакытта да! Ялкау һәм дәрес калдыручылардан кала, барлык студентлар да хореография киңлегендә эшли ала. Ә аларның ни дәрәҗәдә талантлы икәнен бары тик вакыт кына күрсәтәчәк. Әлегә алар студентлар, алар бары тик укый. Безнең заман һәм хәзерге студентларны чагыштырганда, бер аерма да тоймыйм. Студент һәрвакыт үз эше белән кызыксынган укытучысына тартыла!

**– Стажлы укытучы буларак, хореография киңлегендә сезне борчыган мәсьәләләр бармы?**

– Әлбәттә! Аеруча мине яшьләрнең, абитуриентларның, соңыннан студентларның хореография бүлегенә тиешле медицина күзәтүеннән башка укырга керүе һәм белем алуы борчый. Аларның өчтән берендә озакка сузылган терәк-хәрәкәтләнү аппараты авырулары бар (артроз, тез буыннары авыруы). Болар бит 19 яшьтә! Сәбәбе шунда: кайбер очракта балаларны сәләтсез белгечләр биергә өйрәтә. Һәр укучыга индивидуаль караш җитми, төркемләп эшлиләр. Озак еллар эшләү дәверендә шуңа игътибар ителде: сәламәтлеккә зыянны заманча хореография сала. Бу бик еш тезгә егылуга бәйле. Ә бит тезгә дөрес төшү сәнгатен аңлатырга, өйрәтергә кирәк. Биюнең әлеге элементларын башкарганда, артык тырышып җибәрергә дә ярамый. Нәкъ менә шулар бигрәк тә борчый. Шуңа күрә бөтен кешегә дә сәламәтлек һәм уңышлар телим!

Бөек Җиңүгә - 70 ел!

# Хәтер – мәңгелек

**Ландыш ГАРИФУЛЛИНА,**
Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Моның шулай икәнлеген Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышланган «Җиңү уты буыннар хәтерендә» дип аталган конкурс тагын бер кат раслады. 19 нчы май көнне университет музееның актлар залында бәйге җиңүчеләрен бүләкләү чарасы узды.

«Җиңү уты буыннар хәтерендә» иҗади бәйгенең бу елда уздырылуы да бер дә юкка түгел: университет тарихны искә төшерә.

2015 нче ел Бөек Ватан сугышы тематикасына багышланган чараларга аеруча бай. Ветераннар белән очрашулар, төрле акцияләр, концертлар дисеңме... Һәр урамда, һәрбер уку йортында, һәр йортта быел 70 ел элек килгән Җиңү рухы яңартылды дисәм, ялгышмам.

Бирегә белем биргән өлкән буын укытучылар арасында да Ватан өчен көрәштә катнашканнар шактый булган. Кызганыч, бүген инде аларның саны бик кимегән. Заманында утны-суны кичкән егет-кызлар Җиңүнең 70 нче язын тугызынчы дистәне вакыручы чал чәчле ветераннар булып каршылады. Нәкъ менә шуларны онытмау, аларга яшь буынның игътибарын юнәлтү өчен уздырылды да инде алда әйтелгән бәйге.

Студентлар, аспирантлар, мөгаллимнәр арасында уздырылган бу конкурста 20 меңнән артык кеше катнашты. Ул беренчә сайлап алу турыннан торды. «Иләк аша» уздырганнан соң, 20 мең эченнән 70 кеше генә җиңүчеләр исеменә лаек булды. 210 кеше лауреат булу бәхетенә ирешә. Җиңүчеләрне герой-шәһәр Волгоградка бару белән бүләкләсәләр, лауреатларга истәлекле бүләкләр тапшырылды.

Конкурска йомгак ясау көне 19 нчы майга – Татар матбугаты көненә туры килү аеруча игътибарга лаек дип саныйм. Әби-бабайлары, туганнарының сугышка бәйле биографиясен архивлар аша торгызган каләм тибрәтүчеләр азмы-күпме журналист һөнәре белән танышкандыр дип уйлыйм. **Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институтының** татар журналистикасы бүлеге студенты булгач, миңа безнең кафедра студентларының бүләкләнүчеләр исемлегендә булуы аеруча күңелле. Беренче курс студентлары **Мәрьям Насыйрова**, **Эльвира Гайнетдинова** – җиңүче, ә өченче курстан **Раил Садретдинов**, бишенче курстан **Алисә Сабирова** лауреат булды, мин үзем дә шулар арасында.

Гаммәви коммуникация бүлеге житәкчесе, татар журналистикасы кафедрасы мөдире **Васил Гарифуллин** да үзенең котлавында бүләкләүнең 19 нчы май көнендә уздырылуын шатлыклы вакыйга буларак ассызыклап үтте: «Бүген гадәти генә көн түгел, ә татар матбугаты көне дә. Икеләтә бәйрәм булып чыга. Сезне зур җиңүегез белән ихластан котлыйм. Безнең хәтерләрдә Җиңү рухы яшәгәндә, берни онытылмас».

Чыннан да, хәтер – мәңгелек. Әмма Җиңүнең нинди авыр юллар аша килүен юбилей елында гына түгел, гел истә тоту кирәк, минемчә. Безнең йөрәкләрдә хәтер яшәгәндә, Бөек Җиңүнең даны һич онытылмас, буыннан-буынга хатирә булып күчеп барыр.

Студент колагына

# Сессиягә киңәшләр

**Гүзәл АСЫЛОВА,** Социаль-фәлсәфи һәм гаммәви коммуникация институты

Укылганны хәтердә яхшырак калдыру өчен нишләргә?



Әгәр без үзебез теләгән вакытта кайчан да булса укылган яки өйрәнелгән бөтен нәрсәне шундук искә төшерә алсак, бу бик тә яхшы булыр иде. Кызганычка каршы, ул мөмкин түгел. Чөнки хәзер мәгълүмат шаукымы да зур һәм күп нәрсәне кызыксынмыйча гына укыйбыз, ә безнең хәтер кирәкле яки якын вакытта кирәк булачак мәгълүматка гына исәпләнгән.

Беренче чиратта, укыганның мәгънәсенә төшенергә кирәк. «Укырга куштылар» яки «иртәгә миннән сорарга мөмкиннәр» дип кенә уку бернинди дә файда китерми. Әгәр әледән-әле кабатлап тормасаң, әкренләп, укыган «баштан чыгып» китәргә дә мөмкин. Күп еллар дәвамында без даими рәвештә өйрәнгән яки үзебезгә зур тәэсир ясаган әйберләрне генә тиз онытмыйбыз.

Галимнәр фикеренчә, укып ике көн узгач, мәгълүматның бары тик 20 проценты гына хәтердә кала икән. Шунлыктан, укыганны яхшырак истә калдыру өчен, алар кайбер ысуллар кулланырга киңәш итә:

✓ китапларны сайлап кына укыгыз;

✓ әгәр акылыгызны мускуллар кебек эшләтеп тормасагыз, ул көчсезләнә. Укыган, ишеткән, күргән нәрсәләр турында яхшылап уйлагыз. Хәтерегездәге нәтиҗәләр белән чагыштырыгыз;

✓ укыганда игътибарны читкә юнәлтүче әйберләрдән арыныгыз. Шау-шу, тавыш игътибарны кимәтә;

✓ укырга тотынганчы, аның максатын ачыклагыз: бу мәгълүмат ни өчен кирәк?

✓ укыган вакытта хәтердә калдырырга тиешле мәгълүматны билгеләп барырга була. Мәсәлән, вакытлы матбугат басмаларында кирәкле урыннарның астына сызарга мөмкин;

✓ укып бетергәч, сезне кызыксындырган урыннарны яңадан карап чыгарга, аларга бәя бирергә мөмкин.

DARELFONYN университет
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир в.б. - Л.Р.Сабирова
Иҗат коллективы: И.Вәлиев, Р.Габдрахманова, А.Абдрахманова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Фолиант» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Профсоюзная, 17в.